Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Казак Чаллысы авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 11**

Казак Чаллысы авылы 2024 елның 11нче октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 нче маенда «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи айлык хезмәт хакы, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 маддәсе, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә күпьеллык хезмәт өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган кызыксындыруны түләү тәртибе турында" Нигезләмәне раслау хакында 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы карары, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгу сәбәпле Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 10 июлендәге 353 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз

вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Казак Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 нче маенда «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи айлык хезмәт хакы, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 8 номерлы карарына (29.09.2020 ел, № 4 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары» 1 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи айлык хезмәт хаклары күләмнәре» 2 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.3) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата кызыксындыру күләмнәре һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе» 6 нчы кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.4) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә классны чин өчен айлык өстәмә түләү күләмнәре һәм тәртибе» 7 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.5) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондын булдыру тәртибе» 12 нче кушымтасын кушымта итеп бирелщ торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Казак Чаллысы авылы, Иванов ур., 26 йорт; Иванай авылы, Калинин ур., 18 йорт; Бердибәк авылы, Мәктәп ур., 5 йорт; Уреево-Чаллы авылы, Гаврилов ур., 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казак Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Хәсәншин